ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур.,16 нче йорт, Килди авылы,
422586

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

27.11.2025　　Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.　　39

с. Кильдеево

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Килди авылында гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә, Килди авылында гражданнар җыенында кабул ителгән 2025 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Килди авылында гражданнардан үзара салым җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы　　　　Бурдин В.М.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан
муниципаль районы
Килди авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 27
ноябреннән 39 номерлы
карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Килди авылында гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Килди авылында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 01.01.2026 елдан 31.03.2026 елга кадәр Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Килди авылы территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә һәм гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә гамәлгә ашырыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

в) мобилизацияләнгән гражданнар

г) контрактчылар.

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан кергән акчалар Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашырып, яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru/ ссылкасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан
муниципаль районы
Килди авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 27
ноябреннән 39 номерлы
карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № ________________
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И.А.и.
______________________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
______________________________________________________________ нигезендә
Сезгә ________________________ вакытына кадәр
________________________________________________чараларны тормышка ашыруга
______________________________________________________________________________
_____________ сум күләмдә,
түбәндәге реквизитлар буенча:
__________________________________________________
БИК алучы Банк _______________________________________
Сч. № __________________________________
Алучы № Сч. __________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләү билгеләү
_______________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _________________________________________
М. у. (имза) (имза расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - -кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында _______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.А.и. ________________________________________________________
Адрес:
______________________________________________________________________________
Алдым «__» _________________ 20___ ел. ______________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, ертып алына торган өлеше тутырыла һәм Килди авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*